**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1888**
**12.03.2025**

Яр Чаллы шәһәренең «Төзүче» спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы Карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы Карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Төзүче» спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Төзүче» спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2021 елның 12 мартындагы 1715 номерлы Карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 12 мартындагы
1888 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Төзүче» спорт мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе (сум) |
|---|---|---|---|
| I. «Җиңү» футбол манежында массакүләм мәдәни спорт-сәламәтләндерү чаралары оештыру һәм үткәрү | | | |
| 1. | Көндезге вакытта футбол кыры бирү | сәгать | 10000,00 |
| 2. | Көндезге вакытта 1/2 футбол кыры бирү | сәгать | 5000,00 |
| 3. | Көндезге вакытта 1/4 футбол кыры бирү | сәгать | 2500,00 |
| 4. | Кичке вакытта футбол кыры бирү | сәгать | 12000,00 |
| 5. | Кичке вакытта 1/2 футбол кыры бирү | сәгать | 6000,00 |
| 6. | Кичке вакытта 1/4 футбол кыры бирү | сәгать | 3000,00 |
| 7. | Тренажер залы бирү | сәгать | 1000,00 |
| II. Гренада паркында массакүләм мәдәни спорт-сәламәтләндерү чаралары оештыру һәм үткәрү | | | |
| 8. | Бөтенроссия дәрәҗәсендә спорт-сәламәтләндерү чаралары оештыру | 1 матч | 80000,00 |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе
башлыгы вазыйфаларын башкаручы Г.А. Шәфыйкова